МЭР
ГОРОДА ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район,
Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС
ШӘҺӘРЕ ХАКИМЕ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　КАРАР

________________　　г. Иннополис　　№ ________________

17.05.2021　　　　　　　　　　　　　　　　　　№08

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча фикер алышуда катнашу өчен, кешенең уңай тормыш шартларына, Иннополис шәһәрендә яшәүчеләрнең хокукларын үтәү максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан территориаль зоналарны үзгәртү өлешендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Билгеләргә:
2.1. Ачык тыңлауларны үткәрү датасы һәм вакыты - 2021нче елның 7нче июне, 18сәг.00 мин.;
2.2. Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү срогы (озынлыгы)  мондый проект басылып чыккан көннән алып бер айдан  да артмый.
2.3. Үткәрү урыны: Россия, Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Иннополис шәһәре, Парковая урамы, 1нче йорт (Иннополис шәһәренең мәдәни үзәге бинасы-АртСпейс чаралары залы (Event Hall ArtSpace);

2.4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты белән Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Иннополис шәһәре, Спорт урамы, 114 йорт, пом. 1. (дш. – пн. сәгать 9.00 дан 18.00 гә кадәр, җомга -9.00 дан 17.00 гә кадәр) адресы буенча, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында (Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru) танышырга мөмкин;

2.5. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Иннополис шәһәре, Спорт урамы, 114 йорт, ПМ. 1. (дш.-пн. 9.00 дан 18.00 гә кадәр, җомга -9.00 дан 17.00 гә кадәр);

2.6. Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар 2021нче елның 6нчы июненә кадәр 18: 00 сәгатькә кадәр кабул ителә;

2.7. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча тәкъдимнәр яки искәрмәләр үз эченә алырга тиеш: фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, адресын һәм элемтә өчен телефонын (физик затлар өчен) тулы исеме һәм урнашу урынын (юридик затлар өчен); тәкъдим текстын яки искәрмәләрен; тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне кабул итү кирәклеген нигезләп аңлатма язмасын.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Иннополис шәһәре Башкарма комитетына:

3.1. 2021нче елның 21нче маена кадәр әлеге карарны «Волжская Новь» газетасында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru) урнаштырырга;

3.2. 2021нче елның 21нче маена кадәр Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты материалларының экспозициясен Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru) урнаштырырга;

3.3. 2021нче елның 21нче маена кадәр Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турындагы хәбәрләрне Иннополис шәһәре территориясе белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләренә хокукка ия булучыларга җибәрергә;

3.4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча билгеләнгән тәртип һәм әлеге карар белән билгеләнгән сроклар нигезендә ачык тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

3.5. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә

үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар тәмамланганнан соң ун көн эчендә ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә һәм ачык тыңлаулар беркетмәсе тапшырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Р. Р. Шагалиев